


***Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы*** *№ 9,апрель, 2024 ел*




Нәкъ йөз ел элек аваз салган
Куәм мулласының өендә.
Һәм күтәреп улын күккә чөя
Фәтхрахман абый сөенә.
Бар табигать йокыдан уянганда
Бу яшь бала килә дөньяга.
Ир һәм хатын бергә килешәләр
Исемен Самат диеп куярга.

Гүзәл табигатьле, бормаланып аккан Ашыт сулы, чал тарихлы Кала таулары, Әүлияләр каберлеге, Әләшә бәйрәмнәре белән дан казанган Казан арты, Әтнә җирлеге. Арышларның сихри шавын тыңлап үскән Куәм авылы. Күпме данлыклы шәхесләрне берде ул Казан арты, Әтнә ягы: Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, Сибгать Хәким, Самат Шакир, Лена Шагыйрьҗан һ.б. Безнең Куәм авылында С.Шакир кебек эзтабар язучы һәм шагыйрь туу белән мин чын күңелемнән горурланам. Быел аның зур юбилее, аңа 100 яшь булган булыр иде.

Шул уңайдан, мәктәбебездә бик зур чара үтте. Самат ага Шакирның олы юбилеен билгеләп үттек. Бу чарада без, Самат Шакирның тормыш юлы, иҗаты һәм эзтабарлык эшчәнлеге белән таныштык. Аның бик матур шигырьләрен яттан сөйләдек. Төрле җырлар башкардык, биедек.

Чарабызда авылыбызның танылган шагыйрәсе Гөлүсә Батталова катнашты. Ул - Язучылар берлеге әгъзасы. Самат Шакирның әдәбиятта тоткан урыны турында сөйләде. Куәм урта мәктәбе укучыларының талантына сокланды. Киләчәктә Самат Шакирның юлын дәвам итүчеләр дә булыр дип ышанам диде. Кичә үз югарылыгында бик файдалы үтте.

**6 нчы сыйныф укучысы Загидуллина Рәзинә**

## Планетабыз безнең кулларда...

22 нче апрель – Бөтендөнья җир көне. Бу көнне һәр кеше җир шарын саклауга өлеш кертергә бурычлы. Урманнарны, сулыкларны, үсемлекләрне , тере җан ияләрен саклау бездән тора. Табигать безнең ялауга мохтаҗ. Әйдәгез, чисталыкны саклыйк! Киләчәккә табигатебез тагын да безгә бик күп файда китерсен, саф һавалы җирдә яшик.




Тарих бик күп исемнәрне белә,
Бөек шәхесләргә дөнья бай.
Иҗтиһады белән маяк булып,
Мәңге яши, яшьни яшь Тукай!

Үксез тормыш читкә каккан чакта,
Иркәләде сине киң Кырлай.
Моңлы Кырлай урманнары ничек,
Синең шигърияте̦ң шулай бай!

**Тукай! Ул калдырган иҗат мирасы һәм рухи яктылык - безнең горурлыгыбыз.**

## Һәр почмак чиста булсын...

Бүгенге көндә экология актуаль проблемаларның берсе булып тора. Экологик белемнәрне ныгыту, экологик культура булдыру 21 гасыр кешесенең төп бурычы. Безнең табигаткә карашыбыз, җирнең киләчәген билгели. Төрле акцияләрдә катнашып, әйләнә - тирәлекне саклауга үз өлешебезне кертәбез. Мәктәп күләмендә макулатура җыйнау моның ачык мисалы. Табигатьтән дөрес файдалана белергә өйрәнергә кирәк. Без сирәк калган үсемлекләрне саклау турында сөйләшәбез, “Кызыл китап” ка кергән төрләр турында өйрәнәбез, чистарту өмәләрендә катнашабыз. Апрель аенда район күләмендә экологик конференция булып узды. Төрле районнардан килгән укучыларның чыгышлары аерым секцияләрдә тыңланды. Мин үзем туризм секциясендә чыгыш ясадым.

Шулай ук "Будет чисто" төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы тарафыннан уздырылган экологик форумда катнаштык. **«Будет чисто в каждый уголок»** - укучы яшьләр өчен оештырылган проект, эковолонтерлык эшчәнлеге белән таныштык. Анда теоретик белемнәр алдык, практик күнекмәләрне ныгыттык. Аерым командаларда чыгыш ясадык. Бу эшлекле уен формасында узды. Укучылар арасыннан Газизов Сәйдәш, Сибгатова Илвинә үзләрен иң актив катнашучы итеп күрсәттеләр. Форум безгә бик ошады. Алга таба да экология буенча төрле конкурсларга старт алынды. Табигать - уртак йортыбыз, ул имин булсын өчен, барлык кешеләр уйланырга,үз кулыннан килгәнне эшләргә бурычлы.

**9 нчы сыйныф укучысы Калимуллина Гөлия**




## “Киләчәк Паркы” үзенә дәшә

Мин - Сибагатова Ильвина, Анапада - Всероссийский Детский Центрнын «Смена» лагеренда ике атна дәвамында ялда булып кайттым. Без анда поезд белән ике кон бардык. Лагерь «Парк Будущего» һәм профориентация белән бәйле иде. Мин «Архитектура городского пространства» компетенциясе буенча белем алдым. Һәм безне Кара дингез буена алып чыктылар,бик купләр дингезне беренче тапкыр курде. Мина бу лагерь бик ошады.

**8 нче сыйныф укучысы Сибагатова Илвинә**

## Комбайнер булу җиңелме?

Уку елы башыннан һәр пәнҗешәмбе без сыйныф җитәкчебез белән төрле һөнәрләр дөньясына чумабыз, төрле тестлар эшлибез, кем булырга теләвебез турында уйланабыз, рәсемнәр ясыйбыз.

Мин әле кечкенә булсам да, киләчәк һөнәремне авыл хуҗалыгы белән бәйләрмен дип уйлыйм. Комбайнер – авыр хезмәт, ләкин мактауга бик лаек хезмәт. Алар иртәнге 7 дән кичке 12 гә кадәр эшлиләр. Хәзер техника бик көчле, прожекторлары төнлә дә басуны көндезгедәй күрергә мөмкинлек бирә. Мин авыр булса да шушы һөнәрне сайлар идем, чөнки өстәлгә иң кадерле әйбер – икмәк килеп җитүгә аларның керткән өлеше зур. Комбайннар бодай, арыш, кукуруз уралар. Ашлыкны КаМазларга тутыралар, шулай итеп ашлык амбарларга кайта. Ә комбайнер иртәнге 7 дән кичке 12 гә кадәр илне икмәк белән тәэмин итү өчен бертуктаусыз эшли дә эшли...

**5 нче сыйныф укучысы Гиззатуллин Райнур**

## Яз килә

Әй,яз килә! Яз килә,
Кояш нурларын сибә.
Минем нәни песием дә
Яз килгәнгә сөенә.

Өй кыегында бозлардан
Тама тамчылар тып-тып.
Сыерчыклар җырын суза
Тал чыбыгына басып.

**2 сыйныф укучысы Брча Амира**





## Аҗаган 2024

Без 8 нче һәм 9 нчы сыйныф укучылары “Аҗаган 2024” ярышында 3 урын яулап кайттык. Төрле номинацияләр буенча ярыштык һәм грамоталарга ия булдык. «Беренче ярдәм күрсәтү буенча» - Хафизов Кәрим, «Иң оста атучы» - Халикова Азалия, «Иң оста тест биремнәрен үтәүче» - Газизов Сәйдәш, «Иң оста марш атлаучылар» кебек номинацияләрдә без мактауга лаеклы булдык. Ярыш вакытында без йөгердек, сикердек, төрле хәрби - патриотик биремнәрне үтәдек. Хәрби-патриотик ярыш безгә яхшы эмоцияләр генә калдырды.

**8 нче сыйныф укучысы Хәбибуллина Әдилә**

## Сыйныф тормышы

Мәктәп еллары мәңге онытылмас,күңелдә кала торган шатлыклы һәм мәшәкатьсез вакыт.Мәктәп кешегә белем генә бирми,дуслар белән дә таныштыра.

Мин Әтнә районы Күәм авылы урта мәктәбенең 4нче сыйныфында укыйм. Мәктәбебездә укучылар өчен уңайлы шартлар тудырылган.Без дә сыйныф бүлмәбезне тәртиптә тотабыз.Сыйныф бүлмәләре якты һәм җылы.

Без сыйныфта 16 бала. Сыйныфташларым белән бик дус. Без төрле конкурсларда катнашабыз, рәсем ясарга яратабыз, җырлыйбыз, биибез, дәресләргә әзерлексез йөрмибез. Минем сыйныфташларым барысы да актив,уңган, тәртипле.

Мәктәп тормышында да актив катнашабыз. Макулатура җыюда булыштык, дару үләннәре, каен бөресе җыябыз.

Без бик бердәм, дус сыйныф. Дусларым белән музейларга,театрларга бардык. Туган көннәребезне дә бергәләп бәйрәм итәбез.

Мин үземнең сыйныфташларымны , укытучы апамны бик яратам.Алар белән горурланам. Мәктәпне тәмамлап чыккач та аларны сагынып искә алырмын.

**4 нче сыйныф укучысы Хадиева Иделия**




**Кроссвордның җавапларын тап..**